

# УКЫТУЧЫ ЕЛЫ

“Сез иң гүзәл кеше икәнсез”
Чиканас башлангыч мәктәбен төрле елларда тәмамлаган укучылар белән очрашу кичәсе

8 МАРТ 2010 ЕЛ
ЧИКАНАС АВЫЛЫ МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ

Төзеде: Вафина Халидә Фоат кызы

# ЧИКАНАС БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫ БЕЛӘН ОЧРАШУ

- Кеше үзе түгел, ә аның гамәлләре мактауга лаек. (Мишель де Монтень)

# УКЫТУЧЫМ!

- Ак кәгазьдәй сабый күңеленә
- Язмышларны башлап яздыгыз,
- Өмет тулы күпме күзләргә сез
- Яшәү чаткылары салдыгыз.

# ЧИКАНАС БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘБЕНДӘ СОҢГЫ ЧЫГАРЫЛЫШЫМ



# 1989 ЕЛ ЧЫГАРЫЛЫШЫМ



- Мин гөлләрнең күңелегез кебек иң нурлысын
- Сезгә бирер идем.
- Шигырьләрнең, сүзләрегез кебек иң җылысын
- Сезгә бирер идем.
- Укытучым минем!
- Яхшылыкны һич онытмый күңелем!

# ЛИЛИЯ ҺӘМ ФӘНИС КОТЛЫЙ

- Укытучым!
- Олылык, гадилек, тыйнаклык –
- Сездәге иң матур сыйфатлар
- Сезне һәркемгә сөйкемле күрсәткән
- Тагын бер бик күркәм сыйфат бар.
- Сез хезмәт сөясез
- Өлкән дус, киңәшче
- Һәм сердәш буларак
- Кадерле миңа сез.



# БЕРТУГАН ӘҺЛИУЛЛИНАЛАР КОТЛЫЙ



- Өйрәттегез безне бик тырышып
- Бөтен нәрсәләрне үтәргә.
- Авыр булды сезгә укытучым
- Безнең өйрәнгәнне күтәргә.
- Башлангыч сыйныфта укытып
- Чын кеше иттегез безне
- Шат күңел, якты йөз белән
- Килдек без мәктәпкә һәр көнне.

# ӨЧ УКУЧЫБЫЗНЫҢ ӘНИСЕ БУЛАРАК ШӘФИГУЛЛИНА ГӘҮҺӘРИЯ КОТЛЫЙ. БУ КИЧӘНЕ ОЕШТЫРУЧЫ ДА УЛ!



- Кадерле укытучылар! Хәзерге заманда бары тик укыган, яхшы белемле кешеләр генә нәрсәгә булса да ирешә ала. Белем үрләренең беренче баскычын минем балаларым Сезнең белән уңышлы үттеләр. Шатлыкларыбыз, борчуларыбыз уртак булды. Алдагы көннәрегез гел шатлыклы, туачак таңнарыгыз аяз һәм тыныч булсын! Бәхетле, хөрмәтле  сәламәт булыгыз.

## ЯЗМЫШЛАРГА ТАБА ЮЛ САЛДЫМ...
## ЯШӘҮНЕҢ ҮЗЕННӘН КӨЧ АЛДЫМ...



- Син сорама миннән, сорама,
- Җырыңа, дип,каян моң алдың?
- Урау юллар үтеп,
- Авырлыклар кичеп,
- Язмышыма таба юл салдым...
- Яшәүнең үзеннән көч алдым...
- Ш.Җиһангирова

# ДУСЛАРЫМ БАР

- Җан аклыгы чагыла күзләрдә,
- Күңел канат җилпи хыялга.
- Хыялны чын итәр дусларым бар,
- Мин ышанам бүген шуларга.

- Сихри дөнья һаман алга дәшә,
- Бер күкрәп, бер килә яшьнисе,
- Кадерләрен белеп гомерләрнең
- Яшисе дә килә яшисе.





# КЫЗЫМ КОТЛЫЙ



- Кызым минем!
- Җирдә бөтен нәрсә кабатлана,
- Ләкин яшьлек кенә кире кайтмый
- Язмыш, диләр, балаларга күчә.
- Мин сынадым инде әллә ничә.
- Җирдә бөтен нәрсә кабатлана,
- Бәхетләрем генә кабатла ла!
- Бәхетсезлегемне кабатлама...
- Ш.Җиһангирова